# АЛЛАРЫН АЛГА МАНАМ

*Татар халык җыры*

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисәң, кайларга?
Ниләргә сабыр итмисең
Тагын бер-ике айларга?

*Кушымта:*
Ал чия төпләрендә,
Гөл чия төпләрендә.
Сулар сибеп үстерәләр
Тәрәзә төпләрендә.
Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Иркәм китә еракларга —
Сөю утында янам.
Дулкынланып сулар керә
Пароход идәненә.
Ышанмагыз егетләрнең
Яратам дигәненә.

Китәм, диден, читкә киттең,
Чит иде теләкләрең.
Инде хәзер чит җирләрдә
Өзелер үзәкләрең.

*Кушымта.*

Стенада сәгать йөри,
Саный минут исәбен.
Кай җирләрдә йөри икән
Минем алма кисәгем?!

*Кушымта.*